СОВЕТ ЯМАШУРМИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЫСОКОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
422735, Республика Татарстан, Высокогорский район,,с.Ямашурма, ул. Советская, 5

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БИЕКТАУ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЯМАШИРМӘ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
422735, Татарстан Республикасы, Биектау районы,Ямаширмә авылы, Совет ур.,5

Тел./факс: +7(84365) 777-02, e-mail: Yamash.Vsg@tatar.ru

**РЕШЕНИЕ**
**16 август 2024ел**

**КАРАР**
**№ 100**

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Ямаширмә авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Ямаширмә авыл җирлегендә бюджет процессы турында»2021 елның 24 сентябрендәге 34 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы прокуратурасының 23.07.2024 № 02-08-01 протесты нигезендә, Россия Федерациясе Бюджет кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 № 131-ФЗ Федераль законы нигезендә Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Ямаширмә авыл җирлеге Советы КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Ямаширмә авыл җирлегендә бюджет процессы турында» Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Ямаширмә авыл җирлеге Советының 2021 елның 24 сентябрендәге 34 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Ямаширмә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә бюджет процессы турында нигезләмәгә (карарлар редакциясендә 13.12.2021 ел, № 38, 13.02.2024 ел №83 карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 9 статьяның 1 пунктына түбәндәге эчтәлекле 14 пунктча өстәргә:

«14. иҗтимагый финанслар белән идарә итүнең дәүләт интеграцияләнгән мәгълүмат системасында «Электрон бюджет» федераль бюджет акчалары (дәүләт оборона заказына кертелгән капиталь төзелеш объектларыннан һәм күчемсез мөлкәт объектларыннан тыш) капиталь кертемнәрне финанс белән тәэмин итү (финанслаудан) чыганагы булган капиталь төзелеш объектлары һәм күчемсез мөлкәт объектлары турында белешмәләр төзи.».

2. Әлеге карарны интернет челтәрендә «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә: https://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында:

http://pravo.tatarstan.ru.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (халыкка җиткерелгән) көненнән үз көченә керә.

Совет Рәисе,
Авыл җирлеге башлыгы Ф.К.Мохтаров